СОВЕТ
МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**16.05.2025** **Мәлки ав.** **№ 33**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге Советының кайбер карарларының
үз көчләрен югалтуын тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2012 елның 26 июнендәге 26 номерлы;

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2014 елның 14 октябрендәге 40 номерлы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков